Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының дүртенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

25 ноябрь, 2020 ел № 27

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Закон нигезендә, Питрәч муниципаль районының җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү максатларында Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставына таянып **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Питрәч муниципаль районы Советының 2019 елның 25 июлендәге 210 номерлы карары белән расланган (2019 елның 5 декабрендәге 235 номерлы үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Положениегә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.2 п. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Район территориясендә муниципаль милеккә идарә итү, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләр өлкәсендә:

- муниципаль учреждениеләр төзи, муниципаль казна учреждениеләре эшчәнлеген финанс белән тәэмин итә һәм бюджет һәм автоном муниципаль учреждениеләр тарафыннан муниципаль биремне үтәүне финанс белән тәэмин итә, шулай ук муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып ала;

- Районның административ участогында эшләү өчен бина полициянең участок вәкаләтле вәкиле вазыйфасын биләүче хезмәткәргә бирә;

- муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан бирелә торган хезмәтләргә тарифлар һәм, федераль законнарда башкасы каралмаган булса, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан башкарыла торган эшләр билгели;

- 2017 елның 1 гыйнварына кадәр полиция участок уполномоченные вазыйфасын билэүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәрнең күрсәтелгән вазыйфа буенча бурычларын үтәү чорына торак урыны бирә;».

1.2.3 пунктта «муниципаль районның авылара территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыра;» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов